ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.03.2024 Балык Бистәсе штп. № 72пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында сугыш чорына эвакуация чараларын оештыру турында" 05.09.2023 № 307пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнаштыру урыннарда эвакуацияләнгән халыкны кабул итүне, урнаштыруны һәм беренче чиратта тормышны тәэмин итүне планлаштыру идарәсе органнары эшен оештыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында сугыш чорына эвакуация чараларын оештыру турында" 05.09.2023 № 307пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә төзелгән эвакуацияләнгән халыкны урнаштыру пунктлары исемлеген яңа кушымта редакциясендә бәян итәргә;

Нигезләмәнең преамбуласында һәм 1 пунктында “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне мөмкин булган куркыныч зоналардан эвакуацияләүне планлаштыручы муниципаль берәмлекләргә беркетелгән Татарстан Республикасының имин районнары исемлеген раслау турында” 2019 елның 19 июлендәге 016-596 номерлы карары белән» дигән сүзне төшереп калдырырга;

Нигезләмәнең преамбуласында һәм 1 пунктында “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы карары белән" дигән сүзләрне «Халыкны, матди һәм мәдәни

кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү тәртибе турында" 2023 елның 30 ноябрендәге 2056 номерлы карары белән» дигән сүзләр белән алыштырырга".

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының " Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында сугыш чорына эвакуация чараларын оештыру турында" 05.09.2023 № 307пи карарына үзгәрешләр кертү турында" 13.03.2024 №54пи карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д. А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башкарма комитетының
____________________
карары белән расланган

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә оештырылган эвакуацияләнгән халыкны урнаштыру пунктлары исемлеге

| № п/п | Җирлек исеме | Урнаштыру пунктын формалаштыручы (алга таба ПВ), урнашу урыны, адрес | ПВ начальнигы, төп эш урыны буенча вазифасы |
|---|---|---|---|
| 1. | Олы Елга авыл җирлеге | Олы Елга мәдәният йорты 422640, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 24а йорт | Мингалеев Вакиф Нургали улы, мөдир |
| 2 | Зур Мәшләк авыл җирлеге | «Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ 422658, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Зур Мәшләк авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт | Степанова Любовь Алексеевна, «Зур Мәшләк урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ директоры |